ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.04.2019 Алексеевск ш.т.б. № 147

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру турында» 2018 елның 14 декабрендәге 453 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Федераль закон таләпләренә туры китерү максатында

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру турында» 2018 елның 14 декабрендәге 453 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

- 3 номерлы кушымтаның 2.9 пунктындагы 1 абзацы

«Даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршруты 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 26 матдәсендәге 1 өлешенең 1-11 пунктларында каралган көннән,әлеге маршрутлар турында белешмәләр, 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 26 матдәсендәге 1 өлешенең 3-11 пунктларында каралган әлеге маршрутлар турында белешмәләрүзгәртелгән көннән алып, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең тиешле маршрутлары реестрларына кертелгәннән соң билгеләнгән яисә үзгәртелгән дип санала»;

- 1 номерлы кушымтаның 2.3 пункты

«Маршрутлар реестры әлеге Тәртипнең кушымтасы нигезендә алып барыла һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

1) тиешле реестрда даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының теркәү номеры;

2) даими пассажирлар йөртү маршрутының, аңа әлеге маршрутны билгеләгән җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән, тәртип номеры;

3) пассажирлар йөртү маршруты буенча башлангыч тукталыш пункты һәм

соңгы тукталыш пункты атамалары рәвешендә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының исеме яки башлангыч тукталыш пункты һәм әлеге маршрут буенча соңгы тукталыш пункты урнашкан җирлекләр яисә шәһәр округлары исемлекләре;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча арадаш тукталыш пунктлары исемнәре яисә чик буе тукталыш пунктлары урнашкан җирлекләр яки шәһәр округлары исемнәре;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте күздә тотылган урамнар, автомобиль юллары исемнәре;

6) даими пассажирлар йөртү маршрутының озынлыгы;

7) пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе (билгеләнгән тукталыш пунктларында яки, әгәр бу Федераль закон белән тыелмаган булса, даими пассажирлар йөртү маршруты буенча юл хәрәкәте кагыйдәләре белән тыелмагантеләсә кайсы урында);

8) даими рәвештә пассажирлар йөртү төре;

9) транспорт чаралары характеристикалары (транспорт чаралары төрләре, транспорт чаралары класслары, транспорт чараларының экологик характеристикалары, транспорт чараларын эксплуатацияләүнең максималь вакыты, транспорт чараларының пассажирлар йөртү сыйфатына йогынты ясый торган характеристикалары),даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты дәүләт яки муниципаль контракт һәм (яки) ачык бәйгедә катнашучы биргән гариза белән карала, аңа даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелә;

10) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча файдаланырга рөхсәт ителгән һәр класслы транспорт чараларының максималь саны;

11) һәр тукталыш пункты өчен планлаштырылган(даими рәвештә пассажирлар йөртүнең төбәкара маршрутлары өчен башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы тарафыннан билгеләнгән) расписание;

12) даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра башлау датасы;

13) исеме, урнашу урыны (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме һәм булса, атасының исеме, яшәү урыны (шәхси эшмәкәр өчен), даими рәвештә маршрут буенча пассажирлар йөрүченеңсалым түләү буенча идентификация номеры;

14) Россия Федерациясе субъектлары арасында (даими рәвештә пассажирлар йөртүнең чиктәш төбәкара маршрутларына карата) яисә Россия Федерациясе субъекты законында (даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутларының муниципалитетлар арасындагы маршрутларына карата) даими рәвештә пассажирлар йөртүне оештыру турында килешүдә каралган башка мәгълүматлар».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары А. Н. Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазифаларын башкаручы** **Н.П. Чурин**